**СОВЕТ БОЛЬШЕКОВАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422727, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с. Большие Ковали, ул. Школьная, 3

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ КАВАЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422727, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Олы Кавал авылы, Мәктәп урам, 3

тел./факс 8(84365) 60-0-38, e-mail: Bkoval.Vsg@tatar.ru

---

| | |
|---|---|
| **РЕШЕНИЕ** | **КАРАР** |
| **30 сентябрь 2020 ел** | **№ 4** |

## «Олы Кавал авыл җирлеге Советының 2018 елның 30 апрелендәге 91 нче номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Кавал авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында " карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясенең «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының айлык акчалата түләү күләмнәрен арттыру турында» 6.08.2020 елдагы 658 номерлы карары, Олы Кавал авыл җирлеге Уставы, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Кавал авыл җирлеге Советы,

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Кавал авыл җирлеге Советының «үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 30.04.2018 ел, № 76 карары (Советның 27.09.2018 ел № 90 карары редакциясендә) белән расланган айлык акчалата түләү күләмен 2020 елның 1 октябреннән 1,03 тапкырга арттырырга.

2. 2020 елның 1 октябреннән Биектау муниципаль районының Олы Кавал авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең алар биләгән муниципаль хезмәт вазыйфалары нигезендә муниципаль хезмәткәрләрнең «үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 30.04.2018 ел, № 76 карары белән билгеләнгән тәртиптә билгеләнә торган хезмәт хаклары күләмнәрен арттыру (Советның 27.09.2018 ел, № 90 карары редакциясендә).

3. Муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмен исәпләү өчен, әлеге карарның 2 пункты нигезендә, авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладының күләмен 1,03 тапкыр индексацияләргә һәм аны 11498 күләмендә билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Кавал авыл җирлеге Советының 30.04.2018 ел, № 76 «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Кавал авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» карары белән расланган 2 нче кушымта (Советның 2018 елның 27 сентябрендәге 90 номерлы карары редакциясендә), таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Кавал авыл җирлеге башлыгының акчалата бүләкләре күләме»

| Наименование должности | Размеры денежного вознаграждения (в рублях) |
|---|---|
| | 12 группа |
| Глава сельского поселения | 15759 |

5. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Олы Кавал авыл җирлеге бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

6. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Биектау муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ http://pravo.tatarstan.ru/.

7. Әлеге карар 2020 елның 1 октябреннән рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге Башлыгы Ф.К.Гыймадиев